«РАСЛЫЙМ»

«Сәләт» ТРЯИФ

Генераль директоры

_________ Ж. Ш. Сөләйманов

«___» _март_ 2019 ел

**Әдип Әлмир кубогына шахмат турниры үткәрү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Шахмат турнирын оештыручы (алга таба – Турнир) - Татарстан Республикасының «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды (алга таба – «Сәләт» ТРЯИФ), турнирны оештыручы - Сәләт Клубы (алга таба – Клуб).

1.2. Турнирны оештырганда, оештыру комитеты Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары, Россия Федерациясе министрлыкларының һәм ведомстволарының норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы гамәлдәге законнары, Татарстан Республикасы министрлыкларының һәм ведомстволарының норматив-хокукый актлары, әлеге Нигезләмәгә таяна.

**2. Максат һәм бурычлар**

2.1. Максат:

- Сәләт мохитендә шахматны алга таба активлаштыру, яшьләр арасында бу уенга кызыксыну уяту.

2.2. Бурычлар:

- яшьләр арасында шахмат казанышларын пропагандалау, аларны системалы рәвештә шахмат белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;
- сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне ачыклау.

**3.Турнирны оештыру**

3.1. Турнирны оештыру өчен, клуб активистлары арасыннан оештыру комитеты төзелә.

3.2. Оештыру Комитетының бурычлары:

- турнирны үткәрү формасын билгеләү, аның эчтәлеген эшләү һәм өстәмә материаллар әзерләү;
- турнирны үткәрү методикасын эшләү, кирәкле форма һәм бланклар, кирәкле техник документлар әзерләү (мәгълүмати хатлар, турлар бланклары, катнашучылар грамоталары һ. б.);
- катнашучыларга массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирүне оештыру, катнашу өчен гаризалар кабул итү, турнирны уздыру мәсьәләләре буенча элемтәдә тору;
- судьялар командасын формалаштыру;
- турнирга йомгак ясау, аның нәтиҗәләрен билгеләү.

**4. Турнирны үткәрү вакыты һәм урыны**

4.1. Турнир 2019 елның 17-нче мартында Сәләт Йортында (Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт) үткәрелә.
9.30 – катнашучыларны теркәү, 10:30 – турнир башлана.

**5. Казыйлар коллегиясе**

5.1. Турнирны үткәрү өчен казыйлар коллегиясе төзелә. Оештыру тәртибе, казыйлар коллегиясе составы, аның эш регламенты турнирның Оештыру комитеты тарафыннан раслана.
5.2. Турнирның казыйлар коллегиясе:
- турнир кысаларында кагыйдәләр исемлеген раслый;
- турнирны әзерләү һәм үткәрү буенча Оештыру комитетына тәкъдимнәр кертә;
- төп һәм махсус номинацияләрдә җиңүчеләр турында карар кабул итә;
- турнир нәтиҗәләре һәм җиңүчеләр исемлеге оештыру комитетына раслау өчен бирә;
5.3. Турнирның баш казые:
- турнир казыйларына, анда катнашучыларга һәм кунакларга уеннарны уздыру мәсьәләләре буенча консультацияләр бирә, шулай ук турнир казыйлары эше барышында бәхәсле мизгелләр турында карарлар чыгара.

**6. Турнирда катнашучылар**

6.1 Турнирда катнашу өчен барлык теләүчеләр чакырыла: 6-22 яшьлек мәктәп укучылары, ТР уку-укыту йортлары һәм Россия төбәкләре студентлары.
6.2. Турнир һәр төркемдә 4-әр катнашучы булганда үткәрелә.

**7. Турнирны үткәрү кагыйдәләре**

7.1.Турнир ФИДА шахмат уеннары кагыйдәләре буенча үткәрелә.

7.2. Ярышлар өч төркемдә үткәрелә:
– I төркем – 6-11 яшьлек балалар;
– II төркем – 12-22 яшьлек егетләр;
– III төркем – 12-22 яшьлек кызлар.
7.3. II һәм III төркем җиңүчеләре үзара Әдип Әлмир кубогы өчен көрәшәләр.
7.4. Ярышлар «Швейцария системасы» буенча үткәрелә.
7.5. Вакыт контроле: партия азагына кадәр һәр катнашучы өчен 5 минут. Кирәк булган очракта баш казыйлар коллегиясе турнир регламентына үзгәрешләр кертергә хокуклы.
7.6. Җиңүчеләр Әдип Әлмир белән online рәвештә уйныячаклар.

**8. Финанслау**
8.1. «Сәләт» ТРЯИФ турнир оештыруын финанслаштыруны гамәлгә ашыра.
8.2. Турнирда катнашу өчен оргвзнос - 150 сум.

**9. Гаризалар бирү тәртибе һәм вакыты**
9.1. Дәресләргә керү өчен гаризалар түбәндә күрсәтелгән номер буенча кабул ителә яки «Сәләт» берләшмәсенең рәсми сайтында тутырыла – www.selet.biz.
9.2. Турнирда катнашу өчен гариза билгеләнгән үрнәктәге (1-нче кушымта) оештыру комитеты адресына җибәрелә mc.selet@gmail.com яисә «Сәләт» берләшмәсенең рәсми сайтында тутырыла – www.selet.biz.
9.3. Гаризалар турнир башланганчы 3 көн кала кабул ителә.
9.4. Элемтә өчен мәгълүмат +79191078294 – Гүзәл Сабирҗанова.

Кушымта 1

**ГАРИЗА**

Әдип Әлмир кубогына шахмат турнирында катнашу өчен.

| № | Уенчының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча) | Туган көне | Элемтә өчен телефон | Разряд, исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| 3. | | | | |